**СОВЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2025 елның «5» июненнән — № 57-440

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турында нигезләмәне раслау турында» 2021 елның 30 сентябрендәге 14-106 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 28.12.2024 елның 28 декабрендәге 540-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендәТатарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. 1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2021 елның 30 сентябрендәге 14-106 номерлы карары белән расланган (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2021 елның 29 декабрендәге 17-132 номерлы, 2022 елның 8 апрелендәге 20-154 номерлы, 2023 елның 16 мартындагы 32-251 номерлы, 2023 елның 20 апрелендәге 33-266 номерлы, 2023 елның 10 ноябрендәге 38-309 номерлы, 2025 елның 18 февралендәге 52-402 номерлы карарлары редакциясендә) Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турында нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2 өлешендәге 2.25.1. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.25.1. Рейдлы карау дигәндә җитештерү объектларыннан файдалану (эксплуатацияләү) буенча мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен бәяләү максатларында уздырыла торган контроль чарасы аңлашыла, анда берничә контрольдә тотылучы зат урнашкан территориядәге берничә зат файдалана яисә идарә итә.»;

1.2. Нигезләмәнең 2 өлешендәге 2.25.2. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.25.2. Рейдлы карау бары тик прокуратура органнары белән килештереп кенә үткәрелергә мөмкин, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 3, 4, 6, 8 пунктлары, 3 өлеше; 66 статьясындагы 12 өлеше нигезендә уздыру очракларыннан тыш»;

1.3. Нигезләмәнең 2 өлешендәге 2.27.8 пунктында «57 статьясындагы» сүзләреннән соң «һәм 66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләрендә» сүзләрен өстәргә;

1.4. Нигезләмәнең 2 өлешендәге 2.30. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «2.30. Планнан тыш чыгып тикшерү бары тик прокуратура органнары белән килештереп кенә үткәрелергә мөмкин, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 3, 4, 6, 8 пунктлары, 3 өлеше; 66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләре нигезендә уздыру очракларынан тыш»;

1.5. Нигезләмәнең 2 өлешендәге 2.38.2 пунктында «(күзәтчелек)» сүзен төшереп калдырырга;

1.6. Нигезләмәнең 3 өлешендәге 3.6 пунктына түбәндәге эчтәлекле 3.6.3 пункт өстәргә:

«3.6.3. . Мәҗбүри профилактик визит «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 52.1 статьясы нигезендә уздырыла.»;

1.7. Нигезләмәнең 3 өлешенә түбәндәге эчтәлектәге 3.7. пунктын өстәргә:

«3.7. Мәҗбүри профилактик визит контрольдә тотылучы затның аны үткәрүдән баш тартуын күздә тотмый.»;

1.8. Нигезләмәнең 3 өлешенә түбәндәге эчтәлектәге 3.8. пунктын өстәргә:

«3.8. Мәҗбүри профилактик визит уздыру тәмамлангач, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 90 статьясында каралган тәртиптә мәҗбүри профилактик визит уздыру турында акт төзелә(алга таба шулай ук - мәҗбүри профилактик визит акты).»;

1.9. Нигезләмәнең 3 өлешенә түбәндәге эчтәлектәге 3.9. пунктын өстәргә:

«3.9. Контрольдәге зат инициативасы буенча профилактик визит «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 52.2 статьясы нигезендә уздырыла.»;

1.10. Нигезләмәнең 4 өлешендәге 4.2.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2.3. Шикаять судка кадәрге шикаятьнең ярдәмче системасында теркәлгән көннән алып унбиш эш көне эчендә рәис тарафыннан каралырга тиеш.

Контрольдәге затның контроль объектларын хәвеф-хәтәрнең тиешле категориясенә кертү турындагы карарга шикаяте биш эш көненнән дә соңга калмыйча карала.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә муниципаль районы
Башлыгы урынбасары

Н.И.Попкова